# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Минималь хезмәт хакы турында"
Татарстан Республикасы Законын
үзгәртү хакында

Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

I статья. Татарстан Республикасының 1993 елның 20 октябрендәге "Минималь хезмәт хакы турында"гы Законына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Хезмәт хакының минималь күләме Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан билгеләнә, ә Югары Совет сессияләре арасында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдиме буенча, киләчәктә Югары Советта раслау шарты белән, Югары Совет Президиумы тарафыннан билгеләнә. Хезмәт хакының минималь күләме дәүләт гарантиясе булып тора һәм, милек һәм хуҗалык итү рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрнең эш бирүчеләре тарафыннан тәэмин ителә. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең уртак тариф челтәрендәге 1 разрядның айлык ставкасын Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгели".

II статья. Әлеге Законны басылып чыккан көннән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 8 феврале
N 2073 – XII